
КҮҢЕЛ СӘЯХӘТЕ

# Таң калдырды, мине, Казан!

**Татарстан җире — дуслык иле
Зур туй бүген татар илендә
Мәңге яшь бул, Казан
Мәңге яшь кал, Казан
Дуслар күңелендә.**



Казан! Милләтебезнең кыйбласы! Нинди матур, гүзәл шәһәр!

Минем күптәннән инде Казанны күрү теләге бар иде. Хыялыма ирештем. Резеда апа Вәлиеваның чакыруы буенча, 13 енче ноябрьдә Зәйтүнә ханым Валишина белән Казанга киттек. Чит ил автобусы белән кино карый-карый килеп җиткәнебезне сизми дә калдык. Без килеп төштек елга портына. Резеда апа улы Айрат белән безне бик җылы итеп каршы алдылар һәм бай сый — хөрмәт күрсәттеләр ( өч көн буе без аларның хөрмәтле кунагы булдык ).

14 енче ноябрь җомга көн иде, Кол-Шәриф мәчетенә бардык. Ул тышкы һәм эчке ягы белән матур бизәлеше белән безне таң калдырды. Өйлә намазына өлгереп, намаз уку бәхетенә ирештек, вәгазьләр тыңладык.

Кичен Салих Сәйдәшевның зур залына чакыру билеты белән Галина Казанцеваның юбилей кичәсенә бардык. Андагы матурлыкны сөйләп бетерерлек түгел,үзеңә күрергә кирәк.

15 енче көнне чакыру билеты белән "Уникс" залында Нәфгать-Нигматуллинның концертын карадык. Сәхнә бизәлешләре тагын безне таң калдырды.

Казанның бөтен матур урыннарында булдык. "Кабан күле" каршысында Галиәскәр Камал театры. Ул үзенчәлекле бина. Бу ягында Казанның 1000 еллыгына ясалган парк дисеңме? Аларны күреп, искиткеч матурлыкларына сокланып бик озак карап тордык. Шулкадәр матур, бай әчтәлекле икән ул, Казан!

Бик зур рәхмәт әйтәсем килә Зәйтүнә ханым Валишинага, Казанның күренекле шагыйрәсе Резеда Вәлиевага һәм аның улы Айрат Хәлиловка. Ходай исәнлекләрен бирсен, чиксез рәхмәт сезгә, исән-имин яшәгез. Менә шундый кешеләр күбрәк булсын иде шул.

**Нурзимә ГИЗЕТДИНОВА.
Әсәкәй районы,
Әсәкәй авылы.**

**Фотода:**
Резеда Вәлиева белән.

БЕЗГӘ ЯЗАЛАР

# Туган як, мин сине яратам!



Көн озынына бөтен кояш җылысын үзенә алган газиз тупсада утырам. Зур түгәрәк шар акрын гына офык артына кереп югала. Иркен сулап алам да, аңлыйм: башка бер җирдә дә шундый тынычлык җаныма табалмасмын кебек.

Туган як — туган як инде. Биредә һава да татлы, сулар да баллы, кайгылар да юк шикелле.

Туган як. Кызыл таулар... Сез минем тормышымның шаһитләре кебек. Күп күрдегез сез: борынгы заманнан алып, бездән дә соң калып күп нәрсә күрәчәксез әле. Сезнең алдыгызда үстем: кайгыларда да килгәләде, шатлыклар да булды, сагышка күмелгән чаклар да күп булды. Тау башына йөгереп менсәм, җилләр битемне сыпый, чәчләремне тарата. Ә тау җире — йомшак, әни кочагы сыман җылыта, тынычландыра, бар авырулардан дәва бирә.

"Кайтмый калып була мени авылга,әр-яңадан яшәү көчен алырга" Хәзер дә чит, зур шәһәрдән, таш урамнардан авылга кайткач, беренче чиратта тауга йөгерәм, серләремне сөйлим,"Туган як, мин сине яратам!"— дип, тулган күңелемне юатам.

Ә татар телендә сөйләшкәнне ишетсәм, җаным нәкъ коштай талпына башлый. Туган телем минем шундый матур, ягымлы, чишмә кебек яңгырый. Ул минем атам-анам теле, бәгырем, тормышым, туган як моңы.


"Туган телдә дәшсәм генә, туган җирем мине аңлар".

Татар телендә мин сөйләшәм, уйлыйм, аңлашам, аралашам, моңланам, шатланам, эшлим, сөям һәм татар булып яшим.

**Алсу ХАФИЗОВА.
Иске Солтангол-Тольятти.**

МӘДӘНИЯТ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

# Мәскәү кунаклары Богырыслан шәһәрендә



**Февраль аенда Тукай клубында тамашачыларны "Туган як җылысы" дигән күңелле очрашу көтә. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, "Бәллүр каләм" иясе, "Азатлык" радиосының Мәскәү шәһәре журналисты, язучы Нәзифә Каримованың "Сагынасыңмы дип сорыйлар"... исемле китабы буенча фикер алышу була. Бу очрашуда шулаюк Россиянең һәм Татарстанның атказанган артисткасы Наиля Фатехова Нәзифә Каримова шигырьләренә язылган җырлар, татар халык, мәшһүр композиторларыбызның җырларын башкарачак.**

**Татар халкының мәртәбәле шәхесләре белән очрашу беркемне дә битараф калдырмас.**

**Нәзифә Каримованың бер әсәрен тәкъдим итәбез:**

## Яңалык

Безнең авылда көн дә бер яңалык булып тора. Кайсы көнне икәү дә була. Бүген тагы бер яңалык булды. Диләрәләргә читтән кунак кызы кайтты.Бездә аннан шәбрәк яңалыклар да бар ул. Әле кичә генә эти җигеп йөри торган ат колынлады. Аның матурлыгын күрсәгез, исләрегез китәр. Бу да яңалык бит!

Диләрә әйтә, бөтен яңа хәбәр дә яңалык була, ди. Нишләп алай булсын инде? Яңа хәбәрләрненң сөенечлесе дә, көенечлесе дә була. Кайгылы хәбәр яңалыкка кермәсен иде. Кайгы алып килә торган булгач, нинди яңалык була инде ул аннары. Кирмән очында ике ел буе яңа күпер салып бетерә алмыйлар. Салынып беткәч тә яңалык була алмый инде ул. Бар кеше дә белеп бетергәч, шул да булдымы яңалык!

Әле менә авылда иң шәп яңалык булды, Илсурның армиядә хезмәт иткән абыйсы исән-имин өйгә кайтты. Менә, ичмасам, яңалык! Бер кеше көтмәгәндә кайтты да килде.

Рәхәт тә соң авылда яңалык булгач! Иң шәп яңалыкларны клуб янында ишетәсең. Кибеткә әйбер кайтканны да иң беренче кем ишетә? Без, билгеле! Яңалыкны кем тарата? Тагы без инде — вак кызлар. Авылда безне шулай дип йөртәләр.

Менә кибеткә кеше килә башлый, кеше килә башлый… Кибетче җитешеп кенә өлгерсен. Хәер анысы кибетчегә сүз әйтеп булмый. Шалт-шолт гер сала, ялт-йолт башкасын. Кулы кулга йокмый, ничек чутлап өлгерә дисен. Безнең авылда иң башлы кешедер ул? Әле үзе барысын да сөендерә, барысының да күңелен күрә. Инде озак үтми алып кайткан әйберләр дә бетә, кибет тә бушый. Тик соңга калган апалар ашыга-ашыга кибеткә керәләр дә:

— Су чиләкләрең булган икән, Садретдин, калдырмадыңмы? — дип сорыйлар.

— Әй түти! — ди Садретдин абый, әле һаман да китмичә нидер көткән апайларга күз кысып. — Чыгам да карыйм, чыгам да ник килмиләр болар, мин әйтәм, яңалык бит, су чиләкләрем бар иде... менә хәзер бетте шул...

Менә шундый яңалыклар безнең авылда. Аңламассың олыларның яңалыгын. Тик әле мин үзем дә яңалык булырга торам бит. Быел беренче класска укырга керәм. Башка урам кешеләре генә түгел, минә әллә кайчан белгән безнең урамнар да шакатыр әле, букча күтәреп мәктәпкә барганны күргәч:

— И бу гомернең үтүләре! Сиңа да җиде яшь тулдымыни, үскәнем, менә сиңа яңалык! — диярләр.